**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7074**
**28.11.2018**

«Ел эшмәкәре» шәһәр
конкурсын үткәрү турында

Эшмәкәрлекне популярлаштыру һәм Башкарма комитетның 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 нче карары белән расланган «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә 2018 елның декабрендә Яр Чаллы шәһәрендә «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурска әзерлек һәм аны үткәрү чыгымнарын финанслауны 2018 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 20000,00 сум (егерме мең сум 00 тиен) күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7074 нче карарына
1 нче кушымта

«Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсы турында
нигезнамә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә «Ел эшмәкәре» шәһәр конкурсының (алга таба – конкурс) максатларын, оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурсның максаты булып кече һәм урта эшмәкәрлекне популярлаштыру, шулай ук уңышлы тәҗрибәне тарату тора.

3. Конкурсның бурычлары:

1) эшмәкәрлек белән шөгыльләнүнең позитив имиджын формалаштыру һәм популярлаштыру;

2) эшмәкәрлек эшчәнлеген алып баручы актив, сәләтле кешеләрне ачыклау һәм бүләкләү;

3) кабатлап иярү өчен үрнәкләр булдыру.

4. Конкурсның оештыручысы булып Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе тора. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

## 2 бүлек. Конкурсны үткәрү шартлары

5. Конкурста Яр Чаллы шәһәрендә яшәгән һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булган Россия гражданнары катнаша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән шартлар нигезендә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә һәм урта предприятиеләргә караган хуҗалык алып баручы субъектлар (юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр) керә.

6. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- «Ел старты»
- «Профессионал»
- «Мәрхәмәтле йөрәк»
- «Уңышка юл».

7. Конкурсның «Ел старты» номинациясендә катнашуга 2018 елда Яр Чаллы шәһәрендә үз бизнесларын теркәгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чакырыла. Конкурсның «Профессионал» номинациясендә катнашуга Яр Чаллы шәһәрендә теркәлгән һәм кимендә биш ел эшчәнлеген

гамәлгә ашыручы, үсеш стратегиясенең тотрыклылыгын һәм нәтиҗәлелеген күрсәтүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чакырыла.

8. Конкурста катнашуга эшмәкәр мөстәкыйль рәвештә тәкъдим ителә ала, шулай ук номинантларны Яр Чаллы шәһәрендә эшмәкәрлеккә ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар һәм коммерцияле булмаган оешмалар тәкъдим итә ала. Берничә номинациядә катнашу мөмкинлеге бирелә.

9. Конкурста катнашуга түбәндәге компанияләрне тәкъдим итүче затлар кертелми:

1) Россия Федерациясе законнары белән тыелган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

2) алкогольле һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә җитештерелгән эчемлекләр, шулай ук тәмәке, тәмәке эшләнмәләре, тәмәке тарту кирәк-яраклары җитештерү яки сату буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы;

3) азартлы уеннар оештыручы һәм үткәрүче.

10. Конкурста катнашучылар конкурста катнашу өчен, 2018 елның 20 декабренә кадәр әлеге нигезнамәгә кушымтада каралган форма буенча электрон рәвештә конкурсның https://kam.business-gazeta.ru/ рәсми веб-сайтында заявка тутыралар.

11. Конкурста катнашучы заявкада күрсәтелгән мәгълүматларның тулылыгын, дөреслеген һәм законлылыгын гарантияли.

12. Оештыру комитеты конкурс башлану турында шәһәрнең рәсми сайтында www.nabchelny.ru игълан итә.

13. Конкурс этаплап үткәрелә:

1) I этап – 2018 елның 1 декабреннән 25 декабренә кадәр заявкалар җыю һәм https://kam.business-gazeta.ru/ рәсми веб-сайтында интернет тавыш бирү. Интернет-тавыш бирү нәтиҗәләре буенча оештыру комитеты иң күп тавыш җыйган эшмәкәрләрне сайлап ала. Һәр номинациядә 5 әр кеше сайлап алына.

2) II этап – оештыру комитеты әгъзаларының тавыш бирүе. Йомгак ясау I этап тәмамланганнан соң 5 көн эчендә башкарыла;

3) финал – җиңүчеләрне тантаналы төстә бүләкләү. Көне оештыру комитеты тарафыннан II этап тәмамланганнан соң билгеләнә.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

14. Барлык номинацияләрдә конкурста катнашучыларны бәяләү өчен гомуми критерийлар түбәндәгеләр:

1) активлык дәрәҗәсе (конференцияләрдә, күргәзмәләрдә, шәһәр чараларында катнашу);

2) медиалылык (массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмалар, Интернет челтәрендә предприятие һәм аның эшчәнлеге турында киңәйтелгән мәгълүмат);

3) бизнесның актуальлеге, кирәклеге (кешеләр өчен, төрле тармаклар үсеше өчен зарурлыгы һәм кирәк булуы);

4) халыкның мәшгульлеген оештыру (эш урыннары булдыру, эшкә урнаштыру);

5) Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, эш хакы түләү, салымнар түләү, Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле җыемнар һәм башка түләүләр, шулай ук мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминият взнослары буенча бурычлар булмау;

6) эш хакын хезмәткә түләүнең минималь күләменнән кимрәк түләү факты булмау;

7) предприятие үсешенең уңай динамикасы.

15. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты әгъзалары тарафыннан түбәндәге бәяләү критерийлары нигезендә бәяләнә:

| Т/с | Критерий | Максималь бәя |
|---|---|---|
| 1. | Активлык дәрәҗәсе | 10 |
| 2. | Медиалылык | 10 |
| 3. | Бизнесның актуальлеге, кирәклеге | 15 |
| 4. | Халыкның мәшгульлеген оештыру | 15 |
| 5. | Бурычлар булмау | 15 |
| 6. | Эш хакын хезмәткә түләүнең минималь күләменнән кимрәк түләү факты булмау | 15 |
| 7. | Предприятие үсешенең уңай динамикасы | 20 |
| Максималь йомгаклау бәясе | | 100 |

16. Һәр номинациядә җиңүчеләр иң күп уртача баллга ия катнашучылар арасыннан билгеләнә. Уртача балл тиешле заявкага жюри тарафыннан куелган баллар суммасын әлеге заявканы караучы жюри әгъзалары санына бүлеп исәпләп чыгарыла. Берничә претендентның уртача баллары тигез булган очракта, җиңүчеләрне сайлау жюри әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавышы нигезендә үткәрелә.

17. Оештыру комитетының эш нәтиҗәләре беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

18. Һәр номинациядә конкурсның берәр җиңүчесе билгеләнә. Җиңүчеләр истәлекле сувенирлар белән бүләкләнә.

19. Оештыру комитеты өстәмә махсус призларны гамәлгә кую хокукына ия.

20. Конкурс җиңүчеләрен игълан итү һәм бүләкләү конкурс финалындагы тантаналы өлештә башкарыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7074 нче карарына
2 нче кушымта

«Ел эшмәкәре»
конкурсына әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Кропотова<br>Наталия Анатольевна | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| Гыйлаҗева<br>Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| Сәгъдиев<br>Айрат Сәгыйть улы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы |
| Бәшәров<br>Фәрид Рәшид улы | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлегенең генераль директоры (килешенү буенча) |
| Билалов Ринат<br>Вагыйз улы | Бизнес онлайн-Закамье проекты җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Мөхәммәтҗанова<br>Римма Равил кызы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе башлыгы |
| Иванова<br>Венера Бәхтегәрәй кызы | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге Идарәсе каршындагы финанс комитеты рәисе (килешенү буенча) |
| Туктарова<br>Венера Надир кызы | «АКИБАНК» ААҖ идарә Рәисе урынбасары, Шәһәр Совет депутаты (килешенү буенча) |
| Никонов<br>Тимур Викторович | «2ГИС-ЗАКАМЬЕ» ҖЧҖ директоры (килешенү буенча) |
| Балта<br>Андрей Васильевич | «Промвест» ПБ ҖЧҖ генераль директоры (килешенү буенча) |
| Захарова<br>Динара Айрат кызы | «Яшь эшмәкәрләр ассоциациясе» клуб берләшмәсе җитәкчесе (килешенү буенча) |
| Шаһиева<br>Гөлнар Йосыф кызы | Татарстан Республикасы иҗтимагый палатасы әгъзасы, «Перспектива» гражданлык җәмгыяте институтларының үстерү һәм өстәмә белем бирү ресурс үзәге» автономияле коммерцияле |

| | |
|---|---|
| | булмаган оешмасы директоры (килешенү буенча) |
| Дербенева Татьяна Даниловна | «Аудит ТД» фирмасы ҖЧҖ генераль директоры (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

«Ел эшмәкәре»
конкурсы турындагы
нигезнамәгә кушымта

«Ел эшмәкәре» конкурсында катнашуга
заявка

номинацияләр:

| | | |
|---|---|---|
| 1. | «Ел старты» | ☐ |
| 2. | «Профессионал» | ☐ |
| 3. | «Мәрхәмәтле йөрәк» | ☐ |
| 4. | «Уңышка юл» | ☐ |

I. Конкурста катнашучы турында мәгълүмат:

1. Фамилиясе Исеме Атасының исеме ______________________
2. Электрон почтасы __________________________
3. Элемтә телефоны ________________________
4. Компаниядәге вазыйфасы ______________________

II. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты турында мәгълүмат:

1. Оешманың исеме
2. Оештыру-хокукый формасы

☐ ШЭ

☐ ЮЗ

☐ Крестьян-фермерлык хуҗалыгы

3. ИНН:______________________________

4. Кергән акча (сум)
2017 елда – __________
2018 елда (бәя) – _________

5. 2018 елның 9 аенда җитештереп озатылган товар, башкарылган эшләр, хезмәтләр күләменең 2017 елның шул чоры белән чагыштырганда үсеш темплары (%) («Ел старты» номинациясеннән тыш, барысы өчен)
_____________________

Бизнес ачылган моменттан башлап айлар буенча җитештерү күләме динамикасы (сум, %) («Ел старты» номинациясе өчен)

______________________________

5. Хезмәткәрләр саны
2017 елда - __________
2018 елда - __________

6. Хезмәткәрләрнең уртача эш хакы (сум)
2017 елда - __________
2018 елда (бәя) - __________

7. Эш хакын хезмәткә түләүнең минималь күләменнән кимрәк түләү (2018 елның 1 маеннан хезмәткә түләүнең минималь күләме 11163 сумны тәшкил итә)
☐ бар
☐ юк

7. Интернет-тавыш бирү өчен эшчәнлекне (бизнес) кыскача тасвирлау
__________________________________________

8. Шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык
☐ «Шәхси мәгълүматлар турында», 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль закон таләпләре нигезендә, конкурсны оештыручыга минем тарафтан тапшырылган яки тапшырылачак минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм өченче затларга тапшыруга үз ризалыгымны бирәм.

Башкарма комитетның
2018 елның 28 ноябрендәге
7074 нче карарына
3 нче кушымта

«Ел эшмәкәре» конкурсын үткәрүгә
смета

| Т/с | Чыгымнар исеме | Сумма, сум |
|---|---|---|
| 1. | Сувенир продукциясе ясау | 20 000 |
| | барлыгы: | 20 000 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова